Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Кичү авыл җирлегенең Кичү авылында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

18 ноябрь 2019 ел № 1

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кичү авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы, «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кичү авыл җирлегенең Кичү авылында гражданнар җыенының беренче, икенче этаплары тавыш бирү нәтиҗәләре (нәтиҗәләре) турында» 2019 елның 14 ноябрендәге беркетмәсе, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кичү авыл җирлегенең Кичү авылында гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кичү авыл җирлегенең Кичү авылында узган халык җыенын үткәрелгән дип танырга, җыенның нәтиҗәләре - дөрес.

2. «Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Кичү авыл җирлегенең Кичү авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: торак пункт юлларын норматив хәлгә китерү, сметалар төзү һәм техник күзәтчелек үткәрү өчен түләү?» мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Альметьевский вестник» газетасында, Кичү авылы, Үзәк урам, 50 нче йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында бастырырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

Кичү авыл җирлеге башлыгы Г.П.Туманова

КИЧУЙСКИЙ СЕЛЬСКИЙ СОВЕТ